ГЛАВА ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2025 г. Заинск № 173

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврино авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2025 елның 31 октябрендәге 01-09-25426 номерлы хаты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврино авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

1) Уразайкин П.С. – Зәй муниципаль районы Башлыгы урынбасары;
2) Усик О.В. - Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече, гавами тыңлаулар секретаре;
3) Аглямов Р.В. – “Җир төзелеше бюросы” ЖЧҖ директоры (килешү буенча);
4) Кудряшов В.В. - Зәй муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча);
5) Камалиев Ф.Т. - Зәй муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);

6) Павлова Н.Г. - Зәй шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);
7) Шәйхиев Р.Р. - Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе (килешү буенча).

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар уздыру 2025 елның 5 декабреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

**Зәй муниципаль районы башлыгы** **Р.Г. Кәримов**